**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 4 марты № 164

Кама Тамагы муниципаль районы территорияләренә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларын беркетү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү уку-укыту программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» 2020 елның 2 сентябрендәге 458 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы территорияләренә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларын, кушымта нигезендә, беркетергә.

2. Кама Тамагы муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә муниципаль район территорияләрендә гомуми белем бирү оешмаларына беркетелгән төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында белем алырга тиешле балаларны исәпкә алуны тәэмин итәргә, шулай ук бертуганнар һәм (яисә) апа-абыйлары укый торган муниципаль белем бирү оешмаларына башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү хокукын гамәлгә ашыру».

3. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы территорияләренә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларын беркетү турында» Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 10 гыйнварындагы 5 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Мәгариф идарәсе» МКУ, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә гомуми белем бирү оешмалары рәсми сайтларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.В. Сороковнинага йөкләргә.

Җитәкче Р. М. Зәһидуллин

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 4 мартындагы 164 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы территорияләренә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларын беркетү**

| № т/б | Гомуми белем бирү оешмасының исеме | Беркетелгән территория |
|---|---|---|
| 1. | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Кама Тамагы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Кама Тамагы штп, Уразлы авылы, Сатлыган авылы |
| 2. | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Кама Тамагы татар урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Кама Тамагы штп, Бәрлегуҗа, Малаевка, Кече Карамалы, Кече Салтык, Яшелчә, Олы Карамалы , Олы Салтык , Келәр авыллары |
| 3. | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлегенең «Тәмте урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Тәмте авылы, Лабыш, Бортас, Тукай, Ясная Поляна, Ясная Звезда авыллары, Ирекле Хезмәт поселогы, Татар зона тәҗрибә станциясе поселогы, Варварино авылы, Осинники поселогы |
| 4. | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлегенең "Иске Казиле урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Каратал , Иске Казиле авылы, Атабай, Бишалаб, Кыртапа, Кече Бортас, Иске Барыш, Олы Бортас , Балчыклы, Көрәле, Келәнче , Бәки авыллары |
| 5. | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлегенең "Олы Кариле урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Олы Кариле, Бәби, Кече Кариле, Шәпкә, Чаллы, Балтач, Олы Яңасала , Олы Мәрәтхуҗа , Даныш, Абыз авыллары |
| 6. | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш ш.т.п. "Рудник урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Тенеш штп, Кече Мәрәтхуҗа , Антоновка авыллары |
| 7. | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлегенең «Сөйки урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Сөйки авылы, Сөйки Кичүе поселогы, Мордва Каратае, Ишем авыллары |
| 8. | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Василий Петрович Муравьев исемендәге Затон урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Куйбышев Затоны штп |
| 9. | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Красновидово төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Красновидово авылы |

| | | |
|---|---|---|
| 10. | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлегенең "Кирельский төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Кирельский авылы |
| 11. | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлегенең «Келәнче башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Келәнче авылы |
| 12. | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Көрәле башлангыч мәктәп-балалар бакчасы» МБМУ | Көрәле авылы |
| 13. | "Советлар Союзы Герое Чирков Михаил Алексеевич исемендәге Кама Тамагы кадет интернат-мәктәбе»ГБОУ | Куйбышев Затоны штп |